| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2025 г.Лениногорск № 47

Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55нче карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 30 сентябрендәге 1670 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2025 елның 12 ноябрендәге 1783 номерлы карары нигезендә Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Лениногорск муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 55нче карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.2 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затлар, региональ операторлар, төзүчеләр, күпфатирлы йортка турыдан-туры идарә итүне гамәлгә ашыручы күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләре белән карап тоту һәм (яисә) үтәү буенча хезмәтләр күрсәтү шартнамәләре төзелгән затлар тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру тәртибенә таләпләр күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне ремонтлау эшләре, күпфатирлы йортта мондый урын милекчеләренә торак-коммуналь хуҗалык системасында мәгълүмат урнаштыру хокукы бирелгән затлар;».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, законлылык һәм хокук тәртибе; торак-коммуналь хуҗалык һәм инфраструктура үсеше буенча даими комиссияләренә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

М.Н.Гирфанов